**ГЛАВА ИСКЕ-КАЗАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422730, Республика Татарстан, Высокогорский район,, с.Куркачи , ул. Клубная , 4

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ-КАЗАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**
422730, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Коркачык авылы, Клуб ур.,4

Тел./факс: +7(84365) 70-700, e-mail:.Ikaz.Vsg@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**«23» октября 2024 г.** **№ 9**

**Биектау муниципаль районы Иске Казан авыл җирлегенең Татар Урматы авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Биектау муниципаль районының Иске Казан авыл җирлеге Уставының 22 статьясы һәм 2019 елның 21 октябрендәге 167 номерлы карар ( 19.05.2020 редакциясендә) нигезендә г. 187)» Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Иске Казан авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында " Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Иске Казан авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы

Карар кылды:

Биектау муниципаль районы Иске Казан авыл җирлегенең Татар Урматы авылында үзара салымкертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2024 елның 14 ноябрендә 14 сәгатькә билгеләргә.

1. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:Биектау Иске Казан авыл җирлегенең Татар Урматы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2025 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү,ремонтлау, карап тоту.

"КАРШЫ"                                                                                    РИЗА

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Биектау муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә. http://vysokaya-gora.tatarsta№ru/ авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru /кабул ителгән көннән алып 3 көн эчендә.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә

Иске Казан авыл җирлеге Башлыгы                                    Г.Р.Закирова